Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районының «Ленино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Горшково авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР

2019 елның 18 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Ленино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советының 2019 елның 9 октябрендәге 64-127 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге составына керүче торак пунктта гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, 2019 елның 18 ноябрендә Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авыл җирлеге Горшково авылында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча түбәндәге мәсьәләләр каралу турында җыенның беркетмәсе төзелде: «2020 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге бүлектә укучы студентлар, Бөек Ватан сугышы ветеранының тол хатыны, 1 нче группа инвалидлардан тыш) 600 сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән килешәсезме:

- Болын урамына вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү );
- роторлы косилка һәм запас частьләр сатып алу;
- юлларны кардан чистарту;
- җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру)

«РИЗА» «КАРШЫ» «ТЫЕЛУЧЫЛАР».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегендә барлыгы 120 граждан, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар санына 64 граждан кертелгән.
Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Риза» позициясе өчен 44 граждан тавыш бирде;
«Каршы» позициясе өчен 17 граждан тавыш бирде.
«Тыелучылар» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР итте:
1.Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Горшково авылында халык җыены узган, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча кабул ителгән карарны танырга: «2020 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге бүлектә укучы студентлар, Бөек Ватан сугышы ветеранының тол хатыны, 1 нче группа

инвалидлардан тыш) 600 сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән килешәсезме:

- Болын урамына вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү );
- роторлы косилка һәм запас частьләр сатып алу;
- юлларны кардан чистарту;
- җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру)».

3. Әлеге карарны Ленино авыл җирлегенең мәгълүмати стенды аша халыкка җиткерергә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Ленино авыл җирлеге Башлыгы В.М.Веретенников

СОВЕТ ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ